Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының
Кызыл Бистә авыл җирлеге Советы

КАРАР

№ 110-1

29.11.2024 ел

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Кызыл Бистә авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2023 елның 01 ноябрендәге 80-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (2023 елның 05 декабрендәге 81-2 номерлы, 2024 елның 16 февралендәге 88-1 номерлы үзгәрешләр белән)

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2024 елның 12 июлендәге 176-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Кызыл Бистә авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Кызыл Бистә авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2023 елның 01 ноябрендәге 80-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (2023 елның 05 декабрендәге 81-2 номерлы, 2024 елның 16 февралендәге 88-1 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.1 пунктының өченче абзацында «(эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш)» сүзләрен «, эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән һәм һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан арткан җир кишәрлекләреннән тыш, әлеге абзацта күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш»;

1.2. 1.1 пунктның дүртенче абзацында "һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артыграк булган әлеге абзацта күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән тыш" сүзләрен өстәргә.;

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар Кызыл Бистә, Кызыл Вал һәм Щербеть торак пунктларындагы мәгълүмат стендларында, шулай ук Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының интернет челтәрендәге рәсми сайтында http://spasskiy.tatarstan.ru/ һәм хокукый мәгълүматның рәсми порталында https://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән халыкка игълан ителергә тиеш.

Кызыл Бистә авыл җирлеге башлыгы А.В. Алиев.

СОВЕТ КРАСНОСЛОБОДСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ